ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БОРДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

10 декабрь 2018ел № 23

"Гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында»

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Уставы нигезендә 2018 елның 18 ноябрендәге 37/6 номерлы җирле референдумда кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. «Тукай муниципаль районының» Борды авыл җирлеге "муниципаль берәмлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Борды авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артымда калдырам.

Исполнительный комитет БУРДИНСКОГО сельского поселения ИНН 1639032248

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Н.Абдульманова

Кушымта 1
Тукай муниципаль районы
Борды авыл җирлеге
башкарма комитеты
карарына үзгәрешләр кертү хакында
2018 елның 10 декабреннэн № 23

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
“Борды авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе»

1. Тукай муниципаль районының "Борды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен чын тәртип билгели.

2. Узара салым акчалары Түләү 25.03.2019елга кадәр башкарыла , Тукай муниципаль районы “Борды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче 18 яше тулган барлык гражданнар ( җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар күрсәткән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә ) түли .

3. Аерым категория гражданнар өчен:
а) I һәм II төркем инвалидлар;
б) Бөек Ватан сугышы ветераннары;
в) ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар;
г) көндезге формада укучы студентлар;
д) күп балалы гаиләләр.
түләү күләме җирле референдум карарында (гражданнар җыенында) билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Ныклы сәбәпләр булганда, гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне кичектерергә, өч айдан да артмаска мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (белдерү) бланкы Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. һәм авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында : Татарстан Республикасы, Тукай районы, Борды авылы, Школьная урамы, 3 йорт, халыкка игълан итү һәм шулай ук почта элемтәсе аша тапшыру юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымнан алынган акчалары Тукай муниципаль районының «Борды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына килә.

7. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау хокукына ия оешмалар аша, Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша акча күчерү юлы белән башкарыла https://uslugi.tatarstan.ru/.

8. Түләү фактын раслау булып, килү касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Приложение 2
к постановлению
Исполнительного комитета
Бурдинского сельского
поселения Тукаевского
муниципального района
от ________ 2018 г. № ___

ИЗВЕЩЕНИЕ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _______________

об уплате разового платежа по самообложению в бюджет муниципального образования «Бурдинское сельское поселение» Тукаевского муниципального района Республики Татарстан.

Ф.И.О. плательщика_______________________________________________
Адрес: _______________________________________________
На основании _______________________________________________
Вам необходимо уплатить в срок до _______________________ разовый платеж на реализацию мероприятий _______________________________________________
в сумме _____________ рублей,
по следующим реквизитам:_______________________________________________
Банк получателя БИК _______________________________________
Сч. № __________________________________
Получатель Сч. № __________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _______________ ОКАТО _______________
Назначение платежа _______________________________________________

Руководитель _________________ ______________________________
М.П. (подпись) (расшифровка подписи)

----------------- **линия отреза** -------------------------

Извещение (Уведомление) № _________________
об уплате разового платежа по самообложению в бюджет ______________________
*(наименование муниципального образования)*
в сумме ________________ руб.
Ф.И.О. плательщика _______________________________________________
Адрес: _______________________________________________
Получил «__» _______________ 20__ г. ______________________________
(подпись плательщика)

*Примечание. Отрывной корешок заполняется и остается в Исполнительном комитете Бурдинского сельского поселения в случае, если извещение вручается плательщику лично.*